РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » 05 2021 № 155

Аксубаево

«2021 елның II кварталына социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы кыйммәтен раслау турында»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 12.02.2020 ел, № 81 карары белән расланган «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын тормышка ашыру максатларында, Аксубай шәһәр тибындагы поселогында һәм Аксубай муниципаль районында торак урыннарның бер квадрат метры бәясенең «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» КПның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 25.01.2021 №11 үткәргән уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшерү нигезендә, Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның II кварталына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 29,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И.И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев